**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**05.11. 2019 ел.** **№ 93**

Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советының 2017нче елның 23нче ноябрендә кабул ителгән 43нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (2018 нче елның 7 нче маенда 57 нче номерлы карар үзгәрешләре белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 29.09.2009 елдагы 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 23 нче ноябрендәге 43 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяның 2 пунктында түбәндәге сүзләр өстәргә: "(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)";

2. Шәрбән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (httr://aksubayevo.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә һәм 2020нче елның 1 нче гыйнварыннан җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Шәрбән авыл җирлеге Советы рәисе Д.Ә.Шәрифуллин